МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.06.2018 № 11-68

Казан ш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, № 11-51 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 1 март, 2017 ел, № 96 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14 март, 2011 ел, № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында” 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, боерык бирәм:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәне раслау хакында” 09.06.2007ел, №11-51 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 20.06.2011ел, №11-60, 21.09.2011 ел, № 11-83, 22.07.2013 ел, № 17-69, 02.06.2014 ел, № 11-55, 27.10.2017 ел, № 11-103 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә), яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәреш кертергә:

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, №11-51 боерыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.06.2018 ел, №11-68 боерыгы редакциясендә) белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмләр

1. Бу Нигезләмәдә “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан республикасы Законы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 1 март, 2017 ел, № 96 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14 март, 2011 ел, № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының

кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында” 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары) нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы аппаратында (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты аппаратында (алга таба – Казначылык департаменты) дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм кадрлар резервына кертүгә конкурслар оештыру һәм үткәрү тәртибе билгеләнә.

2. Дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм кадрлар резервына кертүгә конкурслар (алга таба – конкурс) үткәрүнең төп бурычлары булып тора:

Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керүенә (алга таба – гражданлык хезмәте) конституцион хокукын тәэмин итү;

Министрлыкның һәм Казначылык департаментының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү;

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү өчен җиңүчене билгеләү;

гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның һәм Казначылык департаментының кадрлар резервын (алга таба – кадрлар резервы) конкурс нигезендә формалаштыру.

3. Конкурс конкурсларда катнашуга кертелгән (алга таба – кандидатлар) Россия Федерациясе гражданнарының (дәүләти гражданлык хезмәткәрләре) һөнәри дәрәҗәсен, аларның гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

4. Конкурс үткәрү турында карар, кадрлар бүлеге начальнигының нигезле доклады буенча, Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә һәм боерык белән рәсмиләштерелә.

5. Конкурс үткәрелми:

а) “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендә дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары вәкаләтләренә билгеле бер срокка билгеләнгәндә;

б) вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, гражданлык хезмәткәрен башка гражданлык хезмәтенә билгеләгәндә;

в) гражданлык хезмәткәрен “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, башка гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

г) гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданин) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

6. Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

а) Министрлык һәм Казначылык департаментының боерыгы белән расланылган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәүгә кагылышлы дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

б) гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

## II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эше тәртибе

2.1. Министрлыкның конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) даими нигездә эшли.

2.2. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – министр) боерыгы белән Министрлыкта һәм Казначылык департаментында даими нигездә эшләүче конкурс комиссияләре раслана.

2.3. Конкурс комиссиясе рәисеннән, рәисе урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясе составына кадрлар бүлегеннән, юридик бүлектән һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә яки кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрә торган структур подразделениедән гражданлык хезмәткәрләре керә.

Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр бәрелеше килеп чыгу ихтималын юкка чыгарырдай итеп булдырыла. Министр карары нигезендә конкурс комиссиясе составы ел саен яңартыла.

2.4. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, конкурс комиссиясенә конкурс комиссиясе рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә. Конкурс комиссиясе секретаре кандидатларны бәяләүдә катнаша һәм конкурс комиссиясе тарафыннан карарлар кабул ителгәндә тавыш бирү хокукына ия була.

Бәйсез экспертлар сыйфатында фәнни, мәгариф оешмалары һәм башка оешмалар вәкилләре җәлеп ителә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләти гражданлык хезмәте һәм кадрлар департаменты, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торчы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законы нигезләмәләреннән чыгып булдырыла.

2.5. Конкурс комиссиясе хокуклы:

а) Министрлыкның структур подразделениеләре начальникларыннан комиссия эше өчен кирәкле мәгълүматлар һәм материаллар соратып алуга;

б) министрга конкурс комиссиясе компетенциядәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертүгә;

в) конкурс комиссиясе утырышларына конкурс комиссиясе әгъзалары булып тормаучы структур подразделениеләр начальникларын һәм /яки аларның урынбасарларын чакыруга.

2.6. Конкурс комиссиясе конкурслар үткәрә:

- гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә;

- Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервын формалаштыру буенча.

2.7.Конкурс комиссиясе утырышы, кирәк булуга карап, конкурс үткәрү турында Министрлык боерык чыгарган очракта, үткәрелә.

Әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, конкурс комиссиясе утырышы, узды, дип санала. Фәкать гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүче әгъзалары катнашында гына конкурс комиссиясе утырышын уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә.

Тавышлар бертигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

2.9. Конкурс комиссиясе конкурста катнашучыларга карата түбәндәге карарларны кабул итә:

а) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен куела торган таләпләргә аеруча туры килә, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләүгә тәкъдим ителә;

б) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен куела торган таләпләргә туры килә, тиешле кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;

в) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен куела торган таләпләргә туры килми.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә.

Конкурс комиссиясе шулай ук гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхес буларак сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар да кабул итүгә хокуклы.

**III. Конкурс үткәрүне оештыру**

3.1. Конкурс ике этапта уздырыла.

3.2. Беренче этапта хәл ителә:

а) конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерүләр әзерләү һәм бастыру;

б) гражданин (гражданлык хезмәткәре) тапшырган документларның һәм мәгълүматларның дөреслеген тикшерү.

3.3. Министрлыкта конкурсны оештыру "Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы) файдалану нигезендә хәл ителә.

3.4. Министрлыкның Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы сайтында һәм "Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы) конкурста катнашу өчен документлар кабул итү белдерү, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасы;

гражданлык хезмәтен үтү урыны;

вакантлы вазыйфа биләү өчен квалификация таләпләре;

гражданлык хезмәтен үтү шартлары;

конкурста катнашу өчен тапшырылырга тиешле документлар исемлеге, шулай ук документларны кабул итү урыны һәм вакыты;

әлеге документларны кабул итү срогы;

конкурсны үткәрүнең якынча датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе;

бәяләү ысуллары турында мәгълүматлар;

гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи регламенты нигезләмәләре – анда вазыйфаи бурычлар, хокуклар һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылык, гражданлык хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре күрсәтелә;

дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталында урнаштырылган башлангыч тестка сылтама;

башка мәгълүмати материаллар.

Башлангыч тест кандидатларның Россия Федерациясенең дәүләт телен (рус теле), Россия Федерациясе Конституциясе нигезләрен, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын ни дәрәҗәдә белүләрен, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә белемнәре һәм осталыкларын бәяләүдән гыйбарәт. Кандидатлар аны бушлай үтә.

Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү һәм конкурс турында мәгълүматлар шулай ук вакытлы матбугат басмасында бастырылып чыгарылырга мөмкин.

Кандидатның башлангыч тестны үтү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе игътибарына алына алмый һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора алмый.

3.5. Конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары

хокуклы.

3.6. Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфасын биләп, конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар бүлегенә министр исеменә гариза тапшыра.

Министрлыкта конкурста катнашырга теләк белдереп, шул ук вакытта башка дәүләт органында гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүче гражданлык хезмәткәре Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар бүлегенә министр исеменә гариза һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 май, 2005 ел, № 667-р боерыгы белән расланган формада анкета (үзе тарафыннан һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан имзаланган), фотосурәте белән, тапшыра.

Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины кадрлар хезмәтенә түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхсән гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 май, 2005 ел, № 667-р боерыгы белән расланган формада тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосурәте белән;

в) паспорт күчермәсе яки аны алыштыручы документ күчермәсе (тиешле документның төп нөсхәсе конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш) – нотариуста яки хезмәт (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган, яки гражданинның (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белеме һәм квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләгенә карап – өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча эштә күтәрелү яки квалификация бирелү турында документлар күчермәләре; гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре – нотариуста яки хезмәт (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган;

д) гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтүгә комачаулардай чирләрдән

интекмәве турында документ;

е) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күздә тотылган башка документлар.

3.7. Гражданин конкурска документлар тапшырганда Министрлыкта персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирә.

3.8. Бу нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында күрсәтелгән документлар Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасы порталында аларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 календарь көне эчендә шәхсән, почта аша яки дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә гражданин (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар бүлегенә тапшырыла.

Электрон рәвештәге документлар “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар белән эшләүгә мәгълүмати технологияләр кертү буенча кайбер чаралар турында” 5 март, 2018 ел, № 227 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 5 март, 2018 ел, № 227 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм федераль дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурсларда катнашу өчен кандидат тарафыннан электрон рәвештәге документлар тапшыру кагыйдәләре нигезендә тапшырыла.

Документларны нигезле сәбәпсез вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданинга (гражданлык хезмәткәре) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документлар нигезле сәбәп белән вакытында тапшырылмаганда, тулы күләмендә тапшырылмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылганда министр аларны кабул итү срокларын күчерүгә хокуклы.

Конкурста катнашуга теләк белдергән гражданнарның (гражданлык хезмәткәрләренең) гаризалары кадрлар бүлеге тарафыннан электрон рәвештә теркәүгә алына.

3.9. Гражданин тарафыннан Министрлыкка яки Казначылык департаментына

тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 5 март, 2018 ел,№ 227 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм федераль дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурсларда катнашу өчен кандидат тарафыннан электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматларны автоматлаштырылган рәвештә тикшерү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

Гражданлык хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген тикшерү фәкать гражданлык хезмәте вазыйфаларының югарыгы төркеменә керүче гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуы очрагында гына хәл ителә.

3.10. Гражданинның (гражданлык хезмәткәре) ризалыгы белән, үзен дәүләт сере яки закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт итү процедурасы башкарыла – конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалануга бәйле булганда.

Гражданин (гражданлык хезмәткәре) дәүләт сере яки закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт итү процедурасы үткәрүдән баш тартса, конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалануга бәйле булганда, конкурска кертелми.

3.11. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, шулай ук гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, бу хакта аңа язмача хәбәр ителә.

Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидат буკарарга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерергә мөмкин.

3.12. Конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында карар, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелгәннән соң, шулай ук, кирәк булган очракта, дәүләт сере яки закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң, министр тарафыннан кабул ителә һәм Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документлар кабул итү төгәлләнгәннән соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә, ә дәүләт сере яки закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын үткәрү срогы министр тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулардай хәлләр билгеләнгән очракта, аңа бу хакта министр тарафыннан, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләрен язмача күрсәтеп, хәбәр ителә. Гражданин конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган очракта, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәр аңа, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

3.13. Министрлык конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 көн кала Министрлыкның рәсми порталында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүматлар, кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган кндидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

3.14.Икенче этапта хәл ителә:

а) кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү;

б) конкурс комиссиясе тарафыннан карарлар кабул итү;

в) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү;

г) Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервына кертү .

3.15. Конкурс үткәрү барышында конкурс комиссиясе тапшырылган документлары нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәүче ысулларыннан файдаланып, конкурс процедуралары нигезендә кандидатларны бәяли, кандидатлар дәгъва кыла торган вазыйфа буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча индивидуаль әңгәмә үткәрү, анкета, төркемләп дискуссияләр үткәрү, реферат язу яки тест уздыруны кертеп.

Конкурс процедуралары барышында кандидатларны бәяләү өчен кимендә өч бәяләү ысулы кулланыла. Кандидат белән тест һәм индивидуаль әңгәмә үткәрү мәҗбүри ысуллар булып тора. Конкурс үткәргәндә бәяләүнең башка ысулларын куллану зарурилыгы, шулай ук эзлеклелеге конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләүдә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфалар башкаруга бәйле вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закрнннарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

3.16. Конкурс процедуралары барышында, кандидатларның конкурс биремнәрен үтәвенә контрольлекне тәэмин итү максатыннан, конкурс комиссиясе вәкилләре катнаша. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырыш башланырга кимендә 3 эш көне кала кандидатларның конкурс биремнәрен үтәү материаллары белән танышырга тиеш. Әлеге материалларның исемлеге конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә..

3.17. Кандидатлар конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе

утырышлары үткәрелгәндә министр карары белән тиешле конкурс процедуралары уздыруны видеотасмага һәм (яки) аудиотасмага яздыру яисә стенограммасын эшләү хәл ителә.

3.18.Конкурс процедуралары барышында тест үткәрелә:

Россия Федерациясенең дәүләт телен, Россия Федерациясе Конституциясе нигезләрен, дәүләт хезмәте һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын ни дәрәҗәдә белүләрен, мәгълүмати-коммуникация технологияләре өлкәсендә белемнәре һәм осталыкларын бәяләү өчен

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төреннән (кадрлар резервын булдыру өчен гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеменнән) чыгып, һөнәри хезмәт эшчәнлеге мәсьәләләре буенча белем һәм күнекмәләрен бәяләү өчен

Тест оештыруны, Министрлыктан Бердәм мәгълүмат кадрлар системасына алынган заявкалар нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты хәл итә.

Тест үткәрүгә заявка кадрлар хезмәте тарафыннан Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында конкурс комиссиясе утырышына кимендә ике атна кала булдырыла.

Тест уздыру “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре” 11 декабрь, 2015 ел, № УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты раслаган тест методикасына туры китерелеп хәл ителә.

3.19. Төркемләшеп дискуссияләр уздыру кандидатлар белән ирекле әңгәмә рәвешендә, үзләренең булачак һөнәри хезмәт эшчәнлегенә кагылышлы конкрет хәлләргә, практик мәсьәләләргә нигезләнеп, хәл ителә.

Конкурс комиссиясе кандидатны үзе югында, җавапларының һәм тәкъдим иткән карарларының ни дәрәҗәдә дөрес булуыннан, дискуссия барышында активлыгыннан һәм фикерләү сәләтеннән чыгып бәяли.

Конкурс комиссиясе әгъзалары дискуссия нәтиҗәләрен бәяли:

5 балл белән – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген эзлекле төстә, тулы күләмендә, тирән һәм сыйфатлы итеп ачып салганда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланганда, дискуссия барышында активлык, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыкларын, аналитик сәләтен, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгын, нигезле карарларны мөстәкыйль кабул итү осталыгын күрсәткәндә;

4 балла белән – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген эзлекле төстә, тулы күләмендә ачып салганда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланып та, берникадәр төгәлсезлекләр һәм кечкенә генә хаталар җибәргәндә, дискуссия барышында активлык, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыкларын, аналитик сәләтен, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгын, карарларны мөстәкыйль кабул итү осталыгын күрсәткәндә;

3 балла белән – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген, эзлекле төстә булса да, тулы күләмендә ачып салмаганда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны кайвакыт дөрес кулланмыйча, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә, дискуссия барышында активлык күрсәтмәгәндә, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыклары, аналитик сәләте, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгы, карарларны мөстәкыйль кабул итү осталыгы уртача дәрәҗәдә булганда;

0 балл – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген ачып сала алмаганда, җавап биргәндә категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланмаганда, зур төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә, дискуссия барышында активлык күрсәтмәгәндә, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыклары, аналитик сәләте, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгы бик түбән дәрәҗәдә булганда.

3.20. Кандидатлар тарафыннан рефератлар язу үзләре дәгъва кыла торган

гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча хәл ителә. Кандидатлар бер үк темага рефератлар яза. Реферат язу өчен аларга бер үк вакыт бирелә. Рефератлар игълан ителгән темага теоретик анализдан, шулай ук авторның нигезле тәкъдимнәреннән торырга тиеш.

Реферат язу яки башка язмача эш башкару өчен гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) вазыйфаи бурычлардан, шулай ук әлеге вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар яки биремнәр кулланыла.

Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү очрагында реферат темасы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрә торган Министрлыкның структур подразделениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә, ә кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрү очрагында – кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеген тормышка ашырып килүче Министрлыкның структур подразделениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм конкурс комиссиясе рәисе белән килештерелә.

Реферат конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

5 балл белән – кандидат теманың эчтәлеген тулы күләмендә, тирән һәм сыйфатлы итеп ачканда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланганда;

4 балл белән – кандидат теманың эчтәлеген тулы күләмендә, тирән һәм сыйфатлы итеп ачып, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланганда, әмма төгәлсезлекләр һәм кечкенә генә хаталар җибәргәндә;

3 балл белән – кандидат теманың эчтәлеген үзлекле төстә, әмма тулы булмаган күләмдә ачып, кайбер урыннарда категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланмаганда, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә;

0 балл – кандидат теманың эчтәлеген ачып сала алмаганда, җавап биргәндә төп категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланмаганда, зур гына төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә.

3.21. Анкета гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) ваыйфаи бурычлардан, шулай ук әлеге вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар буенча үткәрелә.

Анкетага кандидатның элеккеге һөнәри эшчәнлегендәгендә биләгән вазыйфаларында вазыйфаи бурычларын үтәве, һөнәри казанышлары, үзе катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), басма матбугаттагы язмалары, шөгыльләре турында , шулай ук кандидат тарафыннан тапшырылырга мөмкин булган тәкъдимнәр һәм (яки) тәкъдим итү характерындагы хатлар турында сораулар кертелә.

Анкета нәтиҗәләрен бәяләү 5 баллы система буенча хәл ителә.

3.22. Индивидуаль әңгәмә кандидатның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасына ирекле әңгәмә рәвешендә үткәрелә, аның барышында конкурс комиссиясе әгъзалары кандидатка сораулар бирә.

Индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләрен бәяләү 10 баллы система буенча үткәрелә. Индивидуаль әңгәмә йомгаклары буенча конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы кандидатка тиешле балл куя, бу балл Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына №3 кушымта нигезендәге форма буенча тутырыла торган конкурс бюллетененә кертелә, тиешле бәя-билге турында карар кабул итүгә нигезне кыскача гына аңлатып. Конкурс бюллетене конкурс комиссиясе карары (утырыш беркетмәсе) янына урнаштырыла.

3.23. Конкурс комиссиясе тарафыннан, конкурс комиссиясе кандидат белән күзгә-күз карашып индивидуаль әңгәмә үткәрмичә генә, конкурс җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итәргә ярамый.

3.24. Кандидатның йомгаклау баллы индивидуаль әңгәмә, башка конкурс биремнәре нәтиҗәләре һәм тест йомгаклары һәм башка шундый конкурс биремнәрен үтәү йомгаклары буенча кандидат туплаган баллар буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган уртача арифметик баллар суммасы

буларак билгеләнә.

3.25. Конкурс комиссиясе секретаре кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча кандидатларның рейтингын булдыра.

3.26. Конкурс җиңүчесен гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны) билгеләү турында конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының ачык тавыш бирү нигезендәге күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.27. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына №4 нигезендәге форма буенча гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына №5 кушымта нигезендәге форма буенча кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, рәисе урынбасары, секретаре һәм конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

Әлеге карар (беркетмә), конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча кандидатлар туплаган балларны яки алган урыннарын күрсәтеп, кандидатлар рейтингын үз эченә ала.

Карар кандидатны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләүгә яки билгеләүдән баш тартуга нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе тарафыннан кадрлар резервына тупланган баллары максималь баллның кимендә 50 процентын тәшкил иткән кандидатлар арасыннан кандидатлар тәкъдим ителергә мөмкин.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс үткәрелгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс җиңүчесен билгеләү турында Министрлык боерыгы чыгарыла һәм конкурс җиңүчесе белән хезмәт контракты төзелә.

Конкурс комиссиясе гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс җиңүчесенә әйләнмәгән кандидатны Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервына кертү турында карар кабул иткән очракта, әлеге затның ризалыгы белән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы төркемендәге гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен әлеге затны Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервына кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла, бу хакта тиешле боерык чыгарыла.

Кандидатның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс йомгаклары буенча кадрлар резервына кертелүенә ризалыгы язмача яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.2. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен квалификация таләпләренә җавап биргән кандидатлар ачыкланмаган очракта, министр кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итәргә мөмкин.

4.3. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс тәгәлләнгәннән соң 7 көн эчендә кандидатларга язмача рәвештә җибәрелә, шул ук вакытта, конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә. Шушы ук срокта конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтына һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталына урнаштырыла.

4.4. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы дәгъвачыларның документлары һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәгәлләнгәннән соң өч ел эчендә

язмача гариза нигезендә үзләренә кире кайтарып бирелергә мөмкин. Моңа кадәр документлар кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң юкка чыгарыла. Электрон рәвештә тапшырылган конкурста катнашу өчен документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң алар юкка чыгарылырга тиеш.

4.5. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына барып кайту, торак наймы, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б. чыгымнары) кандидатларның үз средстволары хисабына хәл ителә.

4.6. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.06.2018 № 11-68

Казан ш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, № 11-51 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 1 март, 2017 ел, № 96 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14 март, 2011 ел, № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында” 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, боерык бирәм:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәне раслау хакында” 09.06.2007ел, №11-51 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 20.06.2011ел, №11-60, 21.09.2011 ел, № 11-83, 22.07.2013 ел, № 17-69, 02.06.2014 ел, № 11-55, 27.10.2017 ел, № 11-103 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә), яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәреш кертергә:

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, №11-51 боерыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.06.2018 ел, №11-68 боерыгы редакциясендә) белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрү турында нигезләмә

**I. Гомуми нигезләмләр**

1. Бу Нигезләмәдә “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан республикасы Законы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 1 март, 2017 ел, № 96 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14 март, 2011 ел, № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының

кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында" 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары) нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы аппаратында (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты аппаратында (алга таба – Казначылык департаменты) дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм кадрлар резервына кертүгә конкурслар оештыру һәм үткәрү тәртибе билгеләнә.

2. Дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм кадрлар резервына кертүгә конкурслар (алга таба – конкурс) үткәрүнең төп бурычлары булып тора:

Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керүенә (алга таба – гражданлык хезмәте) конституцион хокукын тәэмин итү;

Министрлыкның һәм Казначылык департаментының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү;

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү өчен җиңүчене билгеләү;

гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның һәм Казначылык департаментының кадрлар резервын (алга таба – кадрлар резервы) конкурс нигезендә формалаштыру.

3. Конкурс конкурсларда катнашуга кертелгән (алга таба – кандидатлар) Россия Федерациясе гражданнарының (дәүләти гражданлык хезмәткәрләре) һөнәри дәрәҗәсен, аларның гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

4. Конкурс үткәрү турында карар, кадрлар бүлеге начальнигының нигезле доклады буенча, Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә һәм боерык белән рәсмиләштерелә.

5. Конкурс үткәрелми:

а) “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендә дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары вәкаләтләренә билгеле бер срокка билгеләнгәндә;

б) вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, гражданлык хезмәткәрен башка гражданлык хезмәтенә билгеләгәндә;

в) гражданлык хезмәткәрен “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, башка гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

г) гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданин) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

6. Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

а) Министрлык һәм Казначылык департаментының боерыгы белән расланылган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәүгә кагылышлы дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

б) гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

## II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эше тәртибе

2.1. Министрлыкның конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) даими нигездә эшли.

2.2. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – министр) боерыгы белән Министрлыкта һәм Казначылык департаментында даими нигездә эшләүче конкурс комиссияләре раслана.

2.3. Конкурс комиссиясе рәисеннән, рәисе урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясе составына кадрлар бүлегеннән, юридик бүлектән һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә яки кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрә торган структур подразделениедән гражданлык хезмәткәрләре керә.

Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр бәрелеше килеп чыгу ихтималын юкка чыгарырдай итеп булдырыла. Министр карары нигезендә конкурс комиссиясе составы ел саен яңартыла.

2.4. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, конкурс комиссиясенә конкурс комиссиясе рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә. Конкурс комиссиясе секретаре кандидатларны бәяләүдә катнаша һәм конкурс комиссиясе тарафыннан карарлар кабул ителгәндә тавыш бирү хокукына ия була.

Бәйсез экспертлар сыйфатында фәнни, мәгариф оешмалары һәм башка оешмалар вәкилләре җәлеп ителә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләти гражданлык хезмәте һәм кадрлар департаменты, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торчы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законы нигезләмәләреннән чыгып булдырыла.

2.5. Конкурс комиссиясе хокуклы:

а) Министрлыкның структур подразделениеләре начальникларыннан комиссия эше өчен кирәкле мәгълүматлар һәм материаллар соратып алуга;

б) министрга конкурс комиссиясе компетенциядәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертүгә;

в) конкурс комиссиясе утырышларына конкурс комиссиясе әгъзалары булып тормаучы структур подразделениеләр начальникларын һәм /яки аларның урынбасарларын чакыруга.

2.6. Конкурс комиссиясе конкурслар үткәрә:

- гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә;

- Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервын формалаштыру буенча.

2.7.Конкурс комиссиясе утырышы, кирәк булуга карап, конкурс үткәрү турында Министрлык боерык чыгарган очракта, үткәрелә.

Әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, конкурс комиссиясе утырышы, узды, дип санала. Фәкать гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүче әгъзалары катнашында гына конкурс комиссиясе утырышын уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә.

Тавышлар бертигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

2.9. Конкурс комиссиясе конкурста катнашучыларга карата түбәндәге карарларны кабул итә:

а) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен куела торган таләпләргә аеруча туры килә, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләүгә тәкъдим ителә;

б) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен куела торган таләпләргә туры килә, тиешле кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;

в) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен куела торган таләпләргә туры килми.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә.

Конкурс комиссиясе шулай ук гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхес буларак сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар да кабул итүгә хокуклы.

## III. Конкурс үткәрүне оештыру

3.1. Конкурс ике этапта уздырыла.

3.2. Беренче этапта хәл ителә:

а) конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерүләр әзерләү һәм бастыру;

б) гражданин (гражданлык хезмәткәре) тапшырган документларның һәм мәгълүматларның дөреслеген тикшерү.

3.3. Министрлыкта конкурсны оештыру “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы) файдалану нигезендә хәл ителә.

3.4. Министрлыкның Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы сайтында һәм “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы) конкурста катнашу өчен документлар кабул итү белдерү, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасы;

гражданлык хезмәтен үтү урыны;

вакантлы вазыйфа биләү өчен квалификация таләпләре;

гражданлык хезмәтен үтү шартлары;

конкурста катнашу өчен тапшырылырга тиешле документлар исемлеге, шулай ук документларны кабул итү урыны һәм вакыты;

әлеге документларны кабул итү срогы;

конкурсны үткәрүнең якынча датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе;

бәяләү ысуллары турында мәгълүматлар;

гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи регламенты нигезләмәләре – анда вазыйфаи бурычлар, хокуклар һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылык, гражданлык хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре күрсәтелә;

дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталында урнаштырылган башлангыч тестка сылтама;

башка мәгълүмати материаллар.

Башлангыч тест кандидатларның Россия Федерациясенең дәүләт телен (рус теле), Россия Федерациясе Конституциясе нигезләрен, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын ни дәрәҗәдә белүләрен, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә белемнәре һәм осталыкларын бәяләүдән гыйбарәт. Кандидатлар аны бушлай үтә.

Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү һәм конкурс турында мәгълүматлар шулай ук вакытлы матбугат басмасында бастырылып чыгарылырга мөмкин.

Кандидатның башлангыч тестны үтү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе игътибарына алына алмый һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора алмый.

3.5. Конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары

хокуклы.

3.6. Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфасын биләп, конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар бүлегенә министр исеменә гариза тапшыра.

Министрлыкта конкурста катнашырга теләк белдереп, шул ук вакытта башка дәүләт органында гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүче гражданлык хезмәткәре Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар бүлегенә министр исеменә гариза һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 май, 2005 ел, № 667-р боерыгы белән расланган формада анкета (үзе тарафыннан һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан имзаланган), фотосурәте белән, тапшыра.

Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины кадрлар хезмәтенә түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхсән гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 26 май, 2005 ел, № 667-р боерыгы белән расланган формада тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосурәте белән;

в) паспорт күчермәсе яки аны алыштыручы документ күчермәсе (тиешле документның төп нөсхәсе конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белемен, квалификациясен һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш) – нотариуста яки хезмәт (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган, яки гражданинның (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белеме һәм квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләгенә карап – өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча эштә күтәрелү яки квалификация бирелү турында документлар күчермәләре; гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар күчермәләре – нотариуста яки хезмәт (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган;

д) гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтүгә комачаулардай чирләрдән

интекмәве турында документ;

е) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күздә тотылган башка документлар.

3.7. Гражданин конкурска документлар тапшырганда Министрлыкта персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирә.

3.8. Бу нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында күрсәтелгән документлар Министрлыкның рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасы порталында аларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 календарь көне эчендә шәхсән, почта аша яки дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә гражданин (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар бүлегенә тапшырыла.

Электрон рәвештәге документлар “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар белән эшләүгә мәгълүмати технологияләр кертү буенча кайбер чаралар турында” 5 март, 2018 ел, № 227 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 5 март, 2018 ел, № 227 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм федераль дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурсларда катнашу өчен кандидат тарафыннан электрон рәвештәге документлар тапшыру кагыйдәләре нигезендә тапшырыла.

Документларны нигезле сәбәпсез вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданинга (гражданлык хезмәткәре) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документлар нигезле сәбәп белән вакытында тапшырылмаганда, тулы күләмендә тапшырылмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылганда министр аларны кабул итү срокларын күчерүгә хокуклы.

Конкурста катнашуга теләк белдергән гражданнарның (гражданлык хезмәткәрләренең) гаризалары кадрлар бүлеге тарафыннан электрон рәвештә теркәүгә алына.

3.9. Гражданин тарафыннан Министрлыкка яки Казначылык департаментына

тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 5 март, 2018 ел,№ 227 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм федераль дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурсларда катнашу өчен кандидат тарафыннан электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматларны автоматлаштырылган рәвештә тикшерү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

Гражданлык хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген тикшерү фәкать гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә керүче гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуы очрагында гына хәл ителә.

3.10. Гражданинның (гражданлык хезмәткәре) ризалыгы белән, үзен дәүләт сере яки закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт итү процедурасы башкарыла – конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалануга бәйле булганда.

Гражданин (гражданлык хезмәткәре) дәүләт сере яки закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт итү процедурасы үткәрүдән баш тартса, конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалануга бәйле булганда, конкурска кертелми.

3.11. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, шулай ук гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, бу хакта аңа язмача хәбәр ителә.

Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидат бу карарга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерергә мөмкин.

3.12. Конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында карар, гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелгәннән соң, шулай ук, кирәк булган очракта, дәүләт сере яки закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң, министр тарафыннан кабул ителә һәм Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документлар кабул итү төгәлләнгәннән соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә, ә дәүләт сере яки закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын үткәрү срогы министр тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулардай хәлләр билгеләнгән очракта, аңа бу хакта министр тарафыннан, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләрен язмача күрсәтеп, хәбәр ителә. Гражданин конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган очракта, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәр аңа, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

3.13. Министрлык конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 көн кала Министрлыкның рәсми порталында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүматлар, кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган кндидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

3.14.Икенче этапта хәл ителә:

а) кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү;

б) конкурс комиссиясе тарафыннан карарлар кабул итү;

в) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү;

г) Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервына кертү .

3.15. Конкурс үткәрү барышында конкурс комиссиясе тапшырылган документлары нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәүче ысулларыннан файдаланып, конкурс процедуралары нигезендә кандидатларны бәяли, кандидатлар дәгъва кыла торган вазыйфа буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча индивидуаль әңгәмә үткәрү, анкета, төркемләп дискуссияләр үткәрү, реферат язу яки тест уздыруны кертеп.

Конкурс процедуралары барышында кандидатларны бәяләү өчен кимендә өч бәяләү ысулы кулланыла. Кандидат белән тест һәм индивидуаль әңгәмә үткәрү мәҗбүри ысуллар булып тора. Конкурс үткәргәндә бәяләүнең башка ысулларын куллану зарурилыгы, шулай ук эзлеклелеге конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләүдә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфалар башкаруга бәйле вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закрннарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

3.16. Конкурс процедуралары барышында, кандидатларның конкурс биремнәрен үтәвенә контрольлекне тәэмин итү максатыннан, конкурс комиссиясе вәкилләре катнаша. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырыш башланырга кимендә 3 эш көне кала кандидатларның конкурс биремнәрен үтәү материаллары белән танышырга тиеш. Әлеге материалларның исемлеге конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә..

3.17. Кандидатлар конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе

утырышлары үткәрелгәндә министр карары белән тиешле конкурс процедуралары уздыруны видеотасмага һәм (яки) аудиотасмага яздыру яисә стенограммасын эшләү хәл ителә.

3.18.Конкурс процедуралары барышында тест үткәрелә:

Россия Федерациясенең дәүләт телен, Россия Федерациясе Конституциясе нигезләрен, дәүләт хезмәте һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын ни дәрәҗәдә белүләрен, мәгълүмати-коммуникация технологияләре өлкәсендә белемнәре һәм осталыкларын бәяләү өчен

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе һәм төреннән (кадрлар резервын булдыру өчен гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеменнән) чыгып, һөнәри хезмәт эшчәнлеге мәсьәләләре буенча белем һәм күнекмәләрен бәяләү өчен

Тест оештыруны, Министрлыктан Бердәм мәгълүмат кадрлар системасына алынган заявкалар нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты хәл итә.

Тест үткәрүгә заявка кадрлар хезмәте тарафыннан Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында конкурс комиссиясе утырышына кимендә ике атна кала булдырыла.

Тест уздыру "Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре" 11 декабрь, 2015 ел, № УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты раслаган тест методикасына туры китерелеп хәл ителә.

3.19. Төркемләшеп дискуссияләр уздыру кандидатлар белән ирекле әңгәмә рәвешендә, үзләренең булачак һөнәри хезмәт эшчәнлегенә кагылышлы конкрет хәлләргә, практик мәсьәләләргә нигезләнеп, хәл ителә.

Конкурс комиссиясе кандидатны үзе югында, җавапларының һәм тәкъдим иткән карарларының ни дәрәҗәдә дөрес булуыннан, дискуссия барышында активлыгыннан һәм фикерләү сәләтеннән чыгып бәяли.

Конкурс комиссиясе әгъзалары дискуссия нәтиҗәләрен бәяли:

5 балл белән – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген эзлекле төстә, тулы күләмендә, тирән һәм сыйфатлы итеп ачып салганда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланганда, дискуссия барышында активлык, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыкларын, аналитик сәләтен, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгын, нигезле карарларны мөстәкыйль кабул итү осталыгын күрсәткәндә;

4 балла белән – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген эзлекле төстә, тулы күләмендә ачып салганда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланып та, берникадәр төгәлсезлекләр һәм кечкенә генә хаталар җибәргәндә, дискуссия барышында активлык, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыкларын, аналитик сәләтен, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгын, карарларны мөстәкыйль кабул итү осталыгын күрсәткәндә;

3 балла белән – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген, эзлекле төстә булса да, тулы күләмендә ачып салмаганда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны кайвакыт дөрес кулланмыйча, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә, дискуссия барышында активлык күрсәтмәгәндә, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыклары, аналитик сәләте, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгы, карарларны мөстәкыйль кабул итү осталыгы уртача дәрәҗәдә булганда;

0 балл – кандидат практик мәсьәләнең эчтәлеген ачып сала алмаганда, җавап биргәндә категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланмаганда, зур төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә, дискуссия барышында активлык күрсәтмәгәндә, һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәсендә һәм төрендә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белеме һәм осталыклары, аналитик сәләте, үз фикерен яклый белү һәм эшлекле сөйләшүләр алып бару осталыгы бик түбән дәрәҗәдә булганда.

3.20. Кандидатлар тарафыннан рефератлар язу үзләре дәгъва кыла торган

гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча хәл ителә. Кандидатлар бер үк темага рефератлар яза. Реферат язу өчен аларга бер үк вакыт бирелә. Рефератлар игълан ителгән темага теоретик анализдан, шулай ук авторның нигезле тәкъдимнәреннән торырга тиеш.

Реферат язу яки башка язмача эш башкару өчен гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) вазыйфаи бурычлардан, шулай ук әлеге вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар яки биремнәр кулланыла.

Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү очрагында реферат темасы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрә торган Министрлыкның структур подразделениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә, ә кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрү очрагында – кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеген тормышка ашырып килүче Министрлыкның структур подразделениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм конкурс комиссиясе рәисе белән килештерелә.

Реферат конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

5 балл белән – кандидат теманың эчтәлеген тулы күләмендә, тирән һәм сыйфатлы итеп ачканда, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланганда;

4 балл белән – кандидат теманың эчтәлеген тулы күләмендә, тирән һәм сыйфатлы итеп ачып, категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланганда, әмма төгәлсезлекләр һәм кечкенә генә хаталар җибәргәндә;

3 балл белән – кандидат теманың эчтәлеген үзлекле төстә, әмма тулы булмаган күләмдә ачып, кайбер урыннарда категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланмаганда, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә;

0 балл – кандидат теманың эчтәлеген ачып сала алмаганда, җавап биргәндә төп категорияләрне, төшенчәләр һәм терминнарны дөрес кулланмаганда, зур гына төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәргәндә.

3.21. Анкета гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) ваыйфаи бурычлардан, шулай ук әлеге вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар буенча үткәрелә.

Анкетага кандидатның элеккеге һөнәри эшчәнлегендәгендә биләгән вазыйфаларында вазыйфаи бурычларын үтәве, һөнәри казанышлары, үзе катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), басма матбугаттагы язмалары, шөгыльләре турында , шулай ук кандидат тарафыннан тапшырылырга мөмкин булган тәкъдимнәр һәм (яки) тәкъдим итү характерындагы хатлар турында сораулар кертелә.

Анкета нәтиҗәләрен бәяләү 5 баллы система буенча хәл ителә.

3.22. Индивидуаль әңгәмә кандидатның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасына ирекле әңгәмә рәвешендә үткәрелә, аның барышында конкурс комиссиясе әгъзалары кандидатка сораулар бирә.

Индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләрен бәяләү 10 баллы система буенча үткәрелә. Индивидуаль әңгәмә йомгаклары буенча конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы кандидатка тиешле балл куя, бу балл Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына №3 кушымта нигезендәге форма буенча тутырыла торган конкурс бюллетененә кертелә, тиешле бәя-билге турында карар кабул итүгә нигезне кыскача гына аңлатып. Конкурс бюллетене конкурс комиссиясе карары (утырыш беркетмәсе) янына урнаштырыла.

3.23. Конкурс комиссиясе тарафыннан, конкурс комиссиясе кандидат белән күзгә-күз карашып индивидуаль әңгәмә үткәрмичә генә, конкурс җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итәргә ярамый.

3.24. Кандидатның йомгаклау баллы индивидуаль әңгәмә, башка конкурс биремнәре нәтиҗәләре һәм тест йомгаклары һәм башка шундый конкурс биремнәрен үтәү йомгаклары буенча кандидат туплаган баллар буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган уртача арифметик баллар суммасы

буларак билгеләнә.

3.25. Конкурс комиссиясе секретаре кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча кандидатларның рейтингын булдыра.

3.26. Конкурс җиңүчесен гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны) билгеләү турында конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының ачык тавыш бирү нигезендәге күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.27. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына №4 нигезендәге форма буенча гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31 март, 2018 ел, № 397 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына №5 кушымта нигезендәге форма буенча кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, рәисе урынбасары, секретаре һәм конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

Әлеге карар (беркетмә), конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча кандидатлар туплаган балларны яки алган урыннарын күрсәтеп, кандидатлар рейтингын үз эченә ала.

Карар кандидатны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләүгә яки билгеләүдән баш тартуга нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе тарафыннан кадрлар резервына тупланган баллары максималь баллның кимендә 50 процентын тәшкил иткән кандидатлар арасыннан кандидатлар тәкъдим ителергә мөмкин.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс үткәрелгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс җиңүчесен билгеләү турында Министрлык боерыгы чыгарыла һәм конкурс җиңүчесе белән хезмәт контракты төзелә.

Конкурс комиссиясе гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс җиңүчесенә әйләнмәгән кандидатны Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервына кертү турында карар кабул иткән очракта, әлеге затның ризалыгы белән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы төркемендәге гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен әлеге затны Министрлыкның яки Казначылык департаментының кадрлар резервына кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла, бу хакта тиешле боерык чыгарыла.

Кандидатның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс йомгаклары буенча кадрлар резервына кертелүенә ризалыгы язмача яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.2. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен квалификация таләпләренә җавап биргән кандидатлар ачыкланмаган очракта, министр кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итәргә мөмкин.

4.3. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс тәгәлләнгәннән соң 7 көн эчендә кандидатларга язмача рәвештә җибәрелә, шул ук вакытта, конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә. Шушы ук срокта конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтына һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталына урнаштырыла.

4.4. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы дәгъвачыларның документлары һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәгәлләнгәннән соң өч ел эчендә

язмача гариза нигезендә үзләренә кире кайтарып бирелергә мөмкин. Моңа кадәр документлар кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң юкка чыгарыла. Электрон рәвештә тапшырылган конкурста катнашу өчен документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң алар юкка чыгарылырга тиеш.

4.5. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына барып кайту, торак наймы, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б. чыгымнары) кандидатларның үз средстволары хисабына хәл ителә.

4.6. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.